КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 9 март г.Казань № 213

«2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 26 ноябрь, 1136 нчы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

«2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру чаралары хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 26 ноябрь, 1136 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 28 февраль, 172 нче карары белән кертелгән үзгәрешне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

9 пунктта:

түбәндәге эчтәлекле алтынчы абзац өстәргә:

«шартнамә (дәүләт контракты) суммасының 90 процентыннан артмаган, әмма иң күбе җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары күләмендә – дару чаралары, медицина әйберләре, дәвалану туклануы буенча махсуслаштырылган продуктлары, дезинфекцияләү чаралары, иммунобиологик препаратлары белән тәэмин итү турындагы шартнамәләр (дәүләт контрактлары) буенча (бу пунктның бишенче абзацында каралган очраклардан тыш);»;

алтынчы – унынчы абзацларны шул ук эзлеклелектә җиденче – унберенче абзацлар дип санарга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин